ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

Владимир Путин Көнчыгыш икътисадый форумының пленар сессиясендә илдәге вазгыять турында сөйләде

> 2

ЯШЕЛ БАЙЛЫК

17 сентябрьдә урманчылар һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәчәк

> 2

ЮБИЛЕЙ СЕЗОНЫ

Тинчурин театры тамашачыларын нинди премьералар белән сөендерергә җыена?

> 3

ӘТИ СҮЗЕ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турындагы махсус кушымтасы

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 133 (29100) | Чәршәмбе | 13 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Яңалык

Фастфуд, казылык, газлы су, ит, сөт ризыклары... Тиздән көндәлек тормышыбызда кулланыла торган шундый күп кенә ризыкларның кабында «зарарлы» дигән махсус тамга пәйда булырга мөмкин. Ник дигәндә, Россиядә сәламәтлек өчен зарарлы булган ризыкларны маркировкаларга җыеналар. Проект авторлары, шул рәвешле илдә дөрес тукланучылар саны артыр, күп кенә чирләрне алдан кисәтеп булыр, дип өметләнә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАБЫН КАРАП КАБАСЫ

Бу фикер беренче тапкыр быелның июнендә яңгырады. Россия вице-премьеры Татьяна Голикова Федерация Советы утырышында, симерү очракларын киметү өчен, илдә зарарлы ризыкларны маркировкаларга тәкъдим итте. Аның бу тәкъдимен илнең Сәламәтлек саклау министрлыгы да күтәреп алды. Сүздән эшкә күчеп, проектны әзерли дә башлаганнар инде. Ул гамәлгә керә калса, составында зарарлы матдәләр булган, артык калорияле ризыкларның кабына «зарарлы» дигән мөһер сугылачак. Аны алыргамы, юкмы икәнлеген һәркем үзе хәл итә, билгеле. Әмма проект авторлары, бу тамга күпләрне «уятып» җибәрер, үз сәламәтлегенә җаваплырак карарга этәргеч булыр, дип өметләнә.

Сәламәтлек дигәннән, Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Карина Хәйретдиновага соңгы арада ашказаны, эчәк авыруларыннан зарланып килүчеләр саны арткан. Табиб моның төп сәбәбен нәкъ менә дөрес тукланмауда, зарарлы ризыкларга өстенлек бирүебездә күрә.

– Зарарлы ризыкны күптән маркировкаларга кирәк. Кайчак кеше зарарлы ризык белән генә туклана кебек тоела. Мондый продуктлар симертеп кенә калмый, кандагы холестерин күләмен дә арттыра. Бу исә, үз чиратында, инсульт, инфаркт килеп чыгу ихтималын арттыра. Зарарлы ризык ашаучыларның күбесе гастрит, холецистит, панкреатит кебек ашказаны-эчәк авыруларыннан да интегә. Соңгы арада андый гозерләр белән килүчеләр саны аеруча артты, – ди табиб.

Кибет киштәсендә ризыкларны әледән-әле тикшереп торалар анысы.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе белгечләре әле ел башында гына кибетләрдә сатылган 3,4 мең азык-төлекне тикшергән иде. Монда, нигездә, ипи, камыр ризыклары, ит, сөт ризыклары, консерв, үсемлек мае кебек азык-төлек турында сүз бара. Белгечләр тикшерүдә катнашкан продуктларның 11 проценты зарарлы дигән нәтиҗәгә килгән.

Узган ел идарә белгечләре гомуми авырлыгы 17,5 тонна булган сыйфатсыз ризыкны әйләнештән алган. Чагыштыру өчен: аннан алдагы елда бу сан 40,4 тонна тәшкил иткән булган.

Зарарлы ризыклар маркировкалана башлагач, вазгыять үзгәрерме? Теләчедә яшәүче танылган аш-су блогеры Рафилә Шәмсетдинова бу яңалыкның нәтиҗәле булачагына шикләнеп карый. Үзе азык-төлек алганда иң беренче чиратта аның составына игътибар итә икән.

– Минем өчен азык-төлекнең хәләл һәм ГМОсыз булуы мөһим. Составын караганда анда тезелеп киткән «Е»лар күрсәм, күп очракта ул продукцияне кире киштәгә куям. Зарарлы азык-төлекне маркировкалау бәянең артуына китермәсме икән дигән шик бар. Аннары кабында махсус тамга булганга карап кына зыянлы продуктларны кулланмый калырлар микән? Шул ук тәмәкене дә маркировкалап карадылар бит, ләкин аны барыбер тарталар, – ди Рафилә. – Маркировкалаган очракта да, иң беренче чиратта, зыянлы кушылмалар булган, балалар яратып ашый торган, кибет киштәләрендә күрүгә сорый торган продуктларны маркировкаларга кирәктер, минемчә. Мәсәлән, чипсы, газировка, «киндер», төрле сок, йогыртларны, чөнки анда «зыянлы» дигән маркировка торса, балаларның үзаңнарына тәэсир итәр иде.

Татарстанның атказанган артисты Ләйсән Гыймаева зарарлы ризыкларга тамга сугарга җыенулары турында ишеткәч, шатланып куйды. Ризыкка болай да таләпчән идем, хәзер икеләтә игътибарлырак булачакмын, ди ул.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы төзегән зарарлы ризыклар исемлеге:
- ✓тозлап, каклап, ыслап, төрле ферментлар кушып ясалган ветчина, бекон, сосиска кебек ит ризыклары;
- ✓баллы газлы су, энергетик эчемлекләр;
- ✓составында трансжир майлар (попкорн, чипсы, кетчуп һ.б.) булган, кыздырылган, фритюрда әзерләнгән, баллы ризыклар, камыр ризыклары;
- ✓грильдә яки учакта пешерелгән ит.

– Дөрес туклануга ниндидер зур сынау, сәламәтлеге белән проблемалар аркасында килгән кеше ризык сыйфатына тамгасы булмаса да игътибар итәчәк. Артык сайланып тормаганы исә каптагы күзгә ташланып торган тамгага да игътибар итмәскә мөмкин, – ди Ләйсән. – Үзем азык-төлек алганда иң элек аның хәләл булуына игътибар итәм. Составында чүпрә, шикәр, төрле буягыч матдәләр дә булмаска тиеш. Итне базардан, белгән кешеләрдән генә алабыз. Майонез, кетчуп кебек соуслар да безнең өйдә күптән юк. Ипине дә кукуруз, дөге онынннан чүпрә салмыйча гына үзебез пешерәбез.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Рәис Юлламасы – туры эфирда

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына еллык Юлламасын «ТНВ» телеканалы туры эфирда күрсәтәчәк. Ул 14 сентябрьдә була. Туры эфир 9.55 сәгатьтә башлана.

Татарстан Рәисе Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышында чыгыш ясаячак. Утырышка Дума депутатлары, сенаторлар, Татарстан Хөкүмәте әгъзалары, шулай ук районнарның хакимият башлыклары, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре чакырылган.

Исегезгә төшерәбез: Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына тәүге мөрәҗәгате 2010 елның 13 октябрендә булды. Шуннан бирле ул һәр ел саен үткәрелә. Анда узган елгы эшкә йомгак ясала, барлык дәрәҗәләрдәге хакимиятләрнең эш планнары, шулай ук республиканы үстерүнең төп юнәлешләре билгеләнә.

Үзебезнекен сайлыйлар

Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хезмәткәрләре өчен үзебездә җитештерелгән автомобильләрне конкурс ярдәмендә сайлап алачаклар. Ведомство башлыгы урынбасары Виктор Евтухов әйтүенчә, машиналар сатып алу белән махсус бүлек шөгыльләнәчәк, ә кайсы компаниянең җиңәчәге конкурста хәл ителәчәк.

«Сез Россия машинасына күчеп утырырга әзерме?» дигән сорауга Евтухов үзе: «Президент Владимир Путин бу җәһәттән төгәл бурыч куйды, һәм ул үтәлергә тиеш», – дип җавап биргән.

Дәүләт башлыгы Көнчыгыш икътисадый форумында Россиядә түрәләргә Һиндстаннан үрнәк алырга кирәк, биредә автомобиль сәнәгате нык үсеп килә һәм үзләре җитештергән автомобильләргә өстенлек бирелә, дип билгеләп үткән. 3 августта исә Россия Президенты барлык дәүләт хезмәткәрләрен үзебезнең машиналарда йөрергә өндәде. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин депутатларның бу тәкъдимне тулысынча хуплауларын белдерде.

Бурыч белән шаярма!

Ел башыннан бирле Татарстанда суд приставлары салым түләмәүчеләрдән 495 миллион сум күләмендә бурыч түләткән.

Суд приставлары идарәсе матбугат хезмәтеннән искәртүләренчә, приставлар бурычлының мөлкәтенә арест салырга мөмкин. Бу бурычын түләмәүчегә үз милке белән эш итүне тыюны, кирәк булганда милектән файдалану хокукын чикләүне яки аны тартып алуны күздә тота.

Әйтик, Сарман районында салым түләмәүче бер ир-ат, күчемсез милкен (гомуми мәйданы – 91 кв. м) теркәүгә тыю кертелгәннән соң, 103 мең сум күләмендәге бурычын түләгән.

Көн кадагында

Арта, арта... бензин

55 сум! Бу атнада илнең кайбер төбәкләрендә АИ-92 маркалы бензинның бер литры бәясе әнә шул чиккә җиткән. Татарстанда исә 92ле ягулыкның бер литры 50 сум чамасы тора. Россиядә бензин бәяләре яздан бирле тотрыклы рәвештә үсә, ди белгечләр. Аның үсүдән кайчан туктаячагын фаразларга ашыкмыйлар.

Сентябрь автомобиль йөртүчеләрнең кәефен тәмам кырды. Күзгә кергәннән бирле ягулык салу станцияләрендәге бәяләр көннән-көн югары сикерә. Росстат мәгълүматларына караганда, сентябрьнең беренче атнасында илдә АИ-92 маркалы бензинның бер литры уртача – 50 сум 67 тиен, 95ле бензин – 55 сум 38 тиен, ә дизель ягулыгы бәясе 61 сум 58 тиен тәшкил иткән. Соңгысы, мәсәлән, август азагыннан бирле 1 сумга диярлек кыйммәтләнгән. Машина йөртүчеләр аптырашта. Әйтүләренә караганда, илнең кайбер төбәкләрендә АИ-92 маркалы бензинның бер литры – 55 сум, ә дизель ягулыгы 75 сум тора инде. «Машинада йөрү алтын бәясенә төшә», – ди алар социаль челтәрләрдә.

Татарстанстат хәбәр итүенчә, республикада да узган атнада барыннан да бигрәк дизель ягулыгы кыйммәтләнгән. Бүген аның бер литры уртача 57 сум 75 тиен тора. Бензин хакы да тотрыксыз. Башкаладагы кайбер ягулык салу станцияләрендә АИ-92 маркалы бензинның бер литры 51 сум 60 тиенгә җиткән.

– Көз көне автомобиль ягулыгына бәяләр ел да арта, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Дизель ягулыгына килгәндә, авыл хуҗалыгы эшләре чоры булганлыктан, аңа ихтыяҗ бермә-бер күтәрелә. Бер яктан, әнә шул бәяләр артуга китерсә, икенче яктан, нефть эшкәртү заводлары алдан аяк киенеп, әлеге чорда бензин җитештерүне киметеп, дизель ягулыгын күбрәк чыгара башлый. Ахыр чиктә, бу бензин бәясе кыйммәтләнүгә дә китерә. Бүгенге шартларда нефть һәм газ сәнәгатенә бәйле башка сәбәпләр дә җитәрлек, билгеле.

ТАТАРСТАНДА – ЯГУЛЫК БӘЯЛӘРЕ (сумнарда)

Ягулык	2022 елның декабренә	2023 елның 4 сентябренә
АИ-92	45,96	49,14
АИ-95	49,46	53,38
АИ-98 һәм аннан да югарырак	60,77	64,68
Дизель ягулыгы	54,34	57,74

Татарстанстат мәгълүматлары

Бензин бәясе турында бу көннәрдә Владивостокта узучы Көнчыгыш икътисадый форумында да сөйләштеләр. Россия Президенты Владимир Путин әйтүенчә, ил Хөкүмәте дөнья базарында нефть бәясе артуга бәйле ашыгыч чаралар күрмәгән. Нәтиҗәсе исә күз алдында. «Бүген әлеге мәсьәләдә җитештерүчеләр белән уртак тел таптык», – диде ул форумның пленар утырышында. Илнең энергетика министры Николай Шульгинов сүзләренә караганда, ягулыкны күпләп сату бәяләре валюта курсына һәм кайбер нефть эшкәртү заводларының эшен вакытлыча туктатырга мәҗбүр булуына да бәйле. Машина йөртүчеләр арасындагы ризасызлыкны чамалапмы, «Дәүләт тарафыннан бәяләрне йөгәнләргә тырышу беркайчан да яхшы нәтиҗәгә китерми», – дип тә өстәде Николай Шульгинов.

Ул арада илнең Монополиягә каршы федераль хезмәте ягулык салу станцияләрендәге бәяләрне тикшерә башлаган. Ә Дәүләт Думасы депутатлары бензин һәм дизель ягулыгы бәяләренең иң югары чиген билгеләргә тәкъдим итте. Монысын вакыт күрсәтер. Машина йөртүчеләргә исә түлисе генә кала.

Сүзгә-сүз

Мария ЛЬВОВА-БЕЛОВА, Россия Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

– Исерткеч эчемлекләр һәм наркотиклар белән мавыгу баланы ата-анасыннан аерган, ятимнәр йортларына илткән төп сәбәпләрнең берсе булып тора. Безнең мәгълүматлар буенча, хәзерге вакытта балаларның 40–50 проценты нәкъ менә шул сәбәпле ятим кала. Чарасын күрмәсәк, балалар алга таба мондый оешмаларга эләгүен дәвам итәчәк һәм бу мәсьәлә беркайчан да хәл ителмәячәк.

РОССИЯДӘ – ЮЛ ИМИНЛЕГЕ

2023 елның 6 аенда илдә һәр 100 мең автомобильгә 96,9 авария очрагы туры килгән. РИА Рейтинг мәгълүматларына караганда, юл һәлакәтләрендә зыян күрүчеләр саны (һәлак булганнар яки имгәнүчеләр) һәр 100 меңгә 52,5 кешене тәшкил иткән.

Төбәк	Авария саны, 100 мең машинага	Зыян күрүчеләр саны, 100 мең кешегә
1 Чечня	13,8	6,5
2 Томск өлкәсе	39,8	20,5
...		
51 Татарстан	**111,2**	**48,5**
...		
84 Омск өлкәсе	198,9	91,5
85 Тыва	315,6	107,0
Россия буенча	**96,9**	**52,5**

Саклангынны саклар

Табиблар грипка каршы вакцинация ясауның әһәмиятен ассызыклый. Кичә республика Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов грипптан прививка ясатты. Ул Татарстан халкын, үзеннән үрнәк алып, хәтәр чирдән сакланырга чакырды.

7 сентябрьгә республикада 234 мең чамасы кеше вакцинация узган инде.

Сүз уңаеннан, Татарстанда 4–10 сентябрь көннәрендә ковид белән авырып, хастаханәгә ятучылар саны, аннан алдагы атна белән чагыштырганда, 1,42 тапкыр арткан. Узган атнада 60 кешене дәвалануга салганнар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯГУЛЫККА БӘЯЛӘР ҮСКӘНДӘ

Дөньяда икътисадый хәл катлаулануын дәвам итә. Байден Кытайдагы икътисадый хәлнең начараюын билгеләп үтеп: «Бу Пекинның Тайваньга бәреп керү турындагы карарына китермәс», – дигән өмет белдерде. Кытайлар, чынлап та, кризис сазлыгына көннән-көн ныграк баталар. Алар инде түбәнгә төшүнең дефляция дигән зонасына килеп керде, ягъни Күк асты илендә, ихтыяҗ кимү сәбәпле, бәяләр төшә. Дөньяның күпчелек башка илләрендә инфляция котырына. Соңгы көннәрдә нефть бәясе үсү мотор ягулыгының бәясен югарыга этәрде. Франция Президенты Макрон, ягулык бәяләрен күтәрмәүне сорап, нефть компанияләренә ялвара, диләр. Израильдә бензин бәясен тотрыклы тоту өчен бюджет дефицитын үстерәләр. Шекель курсы түбәнәюгә, «кара алтын»га бәяләр үсүгә карамастан, сентябрьдә мотор ягулыгы үзгәрешсез сатылачак. Ягулык бәясен тотып тору өчен, 2023 ел бюджетында 1,1 миллиард шекель акча каралган булган. Ул акча бетеп килә икән инде. Тотрыклылыкны ел ахырына кадәр саклау өчен, янә йөз миллионлаган шекель акча таләп ителәчәк. 95ле бензин Израильдә ел дәвамында үзгәрешсез калып, 6,86 шекельгә сатыла. Рус сумына күчергәч, 168 сум 48 тиенгә туры килә. Израильдә минималь хезмәт хакы 136 мең 935 сумга тиң икәнен искә алырга кирәк, әлбәттә.

Бензин бәясен тотрыклы тоту өчен, бюджеттан иң күп акчаны Согуд Гарәбстаны бүлә. Җан башына 7 мең доллар акча тотыла икән ул максатларда. Иң арзанлы бензин исә Венесуэлада. Бер айга 120 литр ягулыкны безнең акча белән 40 тиеннән салып була. Шуннан артканы ярты доллар бәядән сатыла.

Ягулыкның кыйммәтләнүенә быелгы гадәттән тыш эссе һава да зур йогынты ясый. Кондиционерларны эшләтү өчен, күп электр энергиясе тотыла. Югары температура нефть эшкәртүче заводларның туктап торуына да китерә. Җиһазлар искергән, экстремаль һава шартларында еш ватылалар. ОПЕК+ илләренең нефть чыгаруны чикләнгән күләмдә тотулары төп рольне уйный, билгеле.

Президент сайлавы алдыннан Байденга түбән инфляция һәм ягулыкка юньле бәяләр кирәк. Ираннан кайбер санкцияләрне алу, Венесуэлага «кара алтын» экспортын рөхсәт итү әлегә көтелгән нәтиҗәләргә китермәде. Инфляциянең тагын бер нигез сәбәбе бар: гадәттән тыш күп итеп акча басу. АКШ тарихында басылган долларларның 80 проценттан артыгragы 2020–2023 еллар аралыгына туры килә. Шулай булгач, бәяләр ник үсмәсен?

Россиядә

ШАТЛЫК ӨСТЕНӘ ШАТЛЫК

Россиянең рәсми мәгълүмат кырыннан сөенечле хәбәрләр килә. Көнбатыштагылар «кара алтын» бәясе күтәрелү сәбәпле үрле-кырлы сикергәндә, федераль министрлыкларда тантана. Финанс министрлыгы нефть-газ керемнәре динамикасы Милли байлык фондына акча өстәргә мөмкинлек бирә башлавын хәбәр итте. Бюджет дефициты планлаштырганнан артмаячак, икътисад үсеше 2 процент булачак. Гомумән, 2025 елга кадәр бюджет дефициты көтелми. Соңгысы турында әйтергә иртәрәк, билгеле, әмма бу хөкүмәтнең финанс блогына алдан шатланып куярга комачауламый.

Тагын бер сөенеч үкчәгә басып килә: сум курсы ныгый башлады. Үткән атнада 98 сумга кадәр күтәрелгән доллар бу атна башында 93кә кадәр арзанайды. Президент киңәшчесе Орешкин, сум девальвациянең югары ноктасын үтте, хәзер доллар курсын 70–80 сумлык коридорга кайтара алачакбыз, дигән белдерү ясады. Көнчыгыш икътисад форумы кулуарларында Орешкин әфәнде, 2024 ел бюджеты профицитлы булачак, дип үк тә әйтеп ташлады, диләр.

Болар барысы да сөендерә. Әмма эйфория озаккамы икән дигән вәсвәсә дә килә күңелгә. Әлегә фанфаралар «кара алтын» бәясе өстендә кагыла. Берничә айдан соң ул бәянең ни рәвешле буласын алдан әйтеп булмый. Азык-төлек булмаган товарларга ихтыяҗ нигездә импорт аша канәгатьләндерелә. Бу тармакта импорт 70 процентка җитә. Белгечләр, импорт кризиска кадәрге күләмгә җитмәде әле, диләр. Нәкъ менә шуңа күрә Үзәк банк хөкүмәт әһелләре белән килешеп үк бетми. Җитештерү ихтыяҗдан артка кала, ди. Бу бәяләр үсешенә китерәчәк дип уйлый. Шул сәбәпле Нәбиуллина конторасы төп ставканы күтәрүне яклый. Бу икътисадны кызудан саклый дип саный. Ставка күтәрелсә, кредит алучылар саны азаер, ихтыяҗ кимер дип көтә. Бу бәяләр тотрыклылыгын вәгъдә итә. Белгечләр шуңа күрә 15 сентябрь утырышында Үзәк банк төп ставканы күтәрер дип фаразлый. Күпчелек 0,5тән алып 3 процентка кадәр өстәлер дип уйлый, ягъни процент ставкасы 15 процентка кадәр җитәргә ихтимал. Схема бик аңлаешлы булса да, ставканың күтәрелүе җитештерүне киметәчәк. Ихтыяҗ яңадан җитештерүдән өскә чыгачак.

Сум курсының ныгуы да әлегә Үзәк банкның валюта сатуны арттыру турындагы карарына бәйле. Сентябрь уртасыннан базарда валюта сатуны ун тапкыр арттырырга ниятләгәннәр иде. Базарлар шуңа доллар бәясен төшерү белән җавап бирде. Үзәк банкның сәүдәне күпме дәвам итәргә җае барлыгын әйтмиләр. Сумның артык ныгуы казнага акча явуны туктатачак, анысы да бар. Шуңа күрә иртәгә ниләр буласын белә алмыйбыз әле.

Эшлекле сөйләшү

ҮТКЕН ҖЫЕН

Ерак Көнчыгышны үстерү, Украина низагы, М12 автомобиль юлы һәм илдән чыгып качучылар. Владивостокта Көнчыгыш икътисадый форумы дәвам итә. Җыенның пленар сессиясендә Россия Президенты Владимир Путин чыгыш ясады. Форумда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Билгеле булганча, әлеге халыкара җыен ел саен үткәрелә. Аның максаты – Ерак Көнчыгышка чит ил инвестицияләрен җәлеп итү һәм Азия – Тын океан төбәкләре (АТР) илләре белән икътисадый хезмәттәшлекне үстерү. Чарада Ерак Көнчыгышка бәйле мәсьәләләр турында да сөйләшәләр.

Форум кысасында Рөстәм Миңнеханов эшлекле очрашулар да үткәрде. Ул «Газпромбанк»ның беренче вице-президенты Павел Бруссер белән аралашты. Очрашуда, дәүләти-хосусый партнерлык кысасында, банкның Татарстанда инфраструктура проектларын финанслауда катнашуы мәсьәләсе каралды. Аерым алганда, юл төзелеше, туризм өлкәләрендәге проектлар буенча фикер алыштылар. Биредә сүз, әйтик, Лаеш шәһәрендә «Казань марина» туристлык инфраструктурасы проектын булдыру турында бара. Ул яр буенда ял итү зонасын төзүне күздә тота.

– «Газпромбанк» – безнең ышанычлы партнер. Хезмәттәшлек өчен кызыклы гына яңа юнәлешләребез бар. Проект бик «тере», әйбәт. Аны тизрәк тормышка ашыру өчен эш төркеме булдырырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рөстәм Миңнеханов «Корпорация АЕОН» холдингына нигез салучы Роман Троценко белән дә очрашты. Алар республикада тормышка ашырылучы проект турында фикер алыштылар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әле күптән түгел генә «Аммоний» заводына баруына бәйле тәэсирләре белән уртаклашты. Ул сәнәгать процессын оештыруны югары бәяләде. Рәис Менделеевскидагы яңартылган химия-технология лицее өчен дә рәхмәт әйтте. Уку йортына яңа җиһазлар сатып алганнар, лабораторияне җиһазлаганнар. Роман Троценко, үз чиратында, әле шушы көннәрдә генә Татарстан башкаласына килгәч, Кытай компаниясе белән зур булмаган экологик чиста электр станцияләре төзү турында килешү имзалауларын сөйләде. «Татарстан Кытай компанияләре омтылган урынга әверелде», – диде ул, Казанда узган тәүге Россия – Кытай халыкара форумына ишарәләп.

Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин белән исә М12 Мәскәү – Казан югары тизлекле трассасын төзү проектын тормышка ашыру турында сөйләштеләр. Чарада Казан мэры Илсур Метшин да катнашты.

Билгеле булганча, форумның пленар утырышында Россия Президенты Владимир Путин бу ел ахырына кадәр М12 трассасы Казанга кадәр салынып бетәчәген әйтте.

Форумның пленар утырышында Владимир ПУТИН әйткән төп фикерләр

kremlin.ru

УКРАИНА ТУРЫНДА
«Сөйләшүләргә килгәндә, әгәр АКШ Украинаны сөйләшүләр алып барырга әзер дип саный икән, Украина Президентының сөйләшүләр үткәрүне тыю турындагы законын кире каксыннар. Беренче адым әнә шул булачак».

М12 ТРАССАСЫ ТУРЫНДА
«Әле күптән түгел генә югары тизлекле юлның Мәскәүдән Арзамаска кадәрге өлешен ачтык. Ел азагына кадәр ул Казанга, ә аннары Екатеринбург һәм Төмәнгә кадәр барып җитәчәк. Әлеге зур проектны һичшиксез дәвам иттерәчәкбез. Югары тизлекле маршрутлар, бердәм транспорт коридорын тәшкил итеп, Ерак Көнчыгыштан Тын океанга кадәр дәвам итәчәк».

БИЗНЕСКА БАСЫМ ТУРЫНДА
«Россиядә бернинди дә деприватизация (шәхси торакны дәүләт яки муниципаль милеккә тапшыру. – **Ред**.) булмаячак. Мин моны ышандырып әйтә алам. Хокук саклау органнарының икътисадта булган хәлләргә бәя бирергә хокукы бар. Әмма бу берничек тә деприватизациягә бәйле түгел. Бизнес вәкилләрен эзәрлекләргә җыенмыйбыз».

ПРЕЗИДЕНТ САЙЛАВЫНДА КАТНАШУЫ ТУРЫНДА
«Гамәлдәге канун нигезендә, парламент сайлау үткәрү турындагы карарны ел ахырында кабул итәргә тиеш. Алар игълан итсен, сайлауның датасы билгеләнсен, менә шуннан соң сөйләшербез».

ТӨП СТАВКА КҮТӘРЕЛҮ ТУРЫНДА
«Август аенда төп ставканы 12 процентка кадәр күтәреп, Үзәк банк бик дөрес эшләде. Бу бик вакытлы чара иде. Әйе, ул кредитлаштыру өчен мөмкинлекләрне киметә, икътисадны, аның үсешен тоткарлый, әмма инфляциягә бәйле куркынычларны киметүнең үтемле чарасы булып тора».

ТОРАКНЫ МӘҖБҮРИ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ ТУРЫНДА
«Бу бик дөрес, торакны иминиятләштерергә кирәк. Әмма моны мәҗбүри эшләтергә ярамый. Халыкка, торакны иминиятләштерегез, дип боера да, аларны акча түләттерә дә алмыйм. Чөнки бу – өстәмә чыгым. Россиядән кала бер генә ил дә гадәттән тыш хәлдән соң торакны торгызу эшен үз өстенә алмый. Әмма без бу эшне күпмедер вакыт дәвам иттерергә тиеш дип саныйм. Халыкның керем дәрәҗәсе бик чамалы әле».

МОБИЛИЗАЦИЯНЕҢ ЯҢА ДУЛКЫНЫ ТУРЫНДА
«Без өлешчә мобилизация үткәрдек. 300 мең кешене хәрби хезмәткә чакырдык. Соңгы 6–7 айда 270 мең кеше үз теләге белән Хәрби көчләргә һәм иреклеләр бүлекчәләренә контракт төзеде. Әлеге эш дәвам итә. Көн саен 1000–1500 кеше контракт төзергә килә. Бу – ил халкы, җәмгыятебезнең үзенчәлеге. Башка илдә бу мөмкиндерме-юкмы, белмим. Гражданнар аңлы рәвештә хәрби хезмәткә бара».

ИЛ АВТОМОБИЛЬЛӘРЕ ТУРЫНДА
«Әйе, бәлки, безнең илдә җитештерелгән автомобильләр «Mercedes» яки «Audi»ларга караганда тыйнаграк күренәдер. Әмма дәүләт башлыклары, дәүләт хезмәткәрләре үзебезнең машиналарга күчеп утырырга тиеш».

ИЛДӘН КИТКӘН МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ ТУРЫНДА
«Төрле исәпләүләр буенча, дәүләт сәясәте белән риза булмыйча 160–170 мәдәният эшлеклесе илдән чыгып киткән. Әйе, сәясәт белән риза булмаска, әмма монда яшәргә һәм бу хакта сөйләргә дә мөмкин бит. Моны беркем тыймый. Әмма илдән китүне өстенрәк күрделәр. Билгеле ки, чит илдә йортлар, фатирлар сатып алып, исәп-хисап счетлары ачып бетерделәр дә хәзер шуны саклап калырга тырышалар. Бу бердәнбер сәбәп түгел, әлбәттә. Читтәге байлыкны саклап калу өчен, алардан тәнкыйтьләүләрен, фаш итүләрен таләп итәләр».

Рәхмәт өчен түгел

АЗИЯ ОМБУДСМЕННАР АССОЦИАЦИЯСЕ КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕ

Татарстан үрнәк. Кеше хокуклары буенча стратегияне гамәлгә ашыру буенча республиканы мактадылар. Мондый документны тәҗрибә буларак өйрәнеп, федераль дәрәҗәгә чыгарырга исәп бар.

Билгеле булганча, Казанда бу көннәрдә Азия Омбудсменнар ассоциациясе Генераль Ассамблеясы утырышы һәм халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Россия төбәкләре һәм төрле илләрдән җыелган кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр тәҗрибә алмашты, республикадагы эшчәнлек белән танышты.

Хакимият белән кеше арасында күпер. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин омбудсменнар турында әнә шулай диде. Соңгы арада аларга мөрәҗәгать итүчеләр артуын да телгә алды.

– Үз җилкәгездә нинди җаваплылык күтәрәсез, башкалар турында уйлап, эшегезне «бу – бурыч» дип башкарасыз, – диде ул. – Сезгә: «Зур рәхмәт!» – дип әйтергә килүчеләр бик сирәк. Гадәттә, «булыш», «бир», «сакла» дип мөрәҗәгать итәләр.

Төрле милләтләрне үзендә сыендырган Татарстанда исә омбудсменнарга аерым игътибар һәм ихтыяҗ. Ник дигәндә, республикада тел, традицияләр, мәдәниятне саклау юнәлешендә омбудсменнарга таянып эш итәләр. Моны Фәрит Мөхәммәтшин да искәртте.

Россиянең Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Татьяна Москалькова сүзләренчә, хәзерге вакытта җәмгыятьнең гаделлеккә, милли үзенчәлекне саклауга ихтыяҗы аеруча зур. Шуңа да, Татьяна Москалькова әйтүенчә, яңа технологияләрне кулланып, халыкка тагын да якынаю ысулларын карарга кирәк. Ул халыкка хокукый белем бирүне оештыру һәм хокук яклау эшен оештыруда Федераль дәүләт мәгълүмат системасының сынау рәвешендә эшләтеп җибәрелүе турында да хәбәр итте.

– Шул рәвешле безнең мөмкинлекләребездән файдаланырга теләүчеләргә аларны куллану өчен тагын да җиңелрәк булыр иде, – диде ул.

Сүз уңаеннан, үзенә мөрәҗәгать итүчеләр санын да яшермәде федераль кунак. 2022– 2023 еллар аралыгында 270000 кешенең хокукларын яклаганнар. 2023 елның алты аенда 43106 мөрәҗәгать кабул ителгән. Москалькова әйтүенчә, мөрәҗәгать итүчеләрнең зарлары күбесенчә социаль сорауларга, медицина ярдәменә, дарулар белән тәэмин итү, экология, торак мәсьәләләренә, төрмәдә утыручыларның хокукларына бәйле.

Азия Омбудсменнар ассоциациясе президенты, Пакьстанның Федераль омбудсмены Эджаз әфәнде Әхмәт Куреши Казандагы җыенның әһәмиятен билгеләп үтте.

– Бу көннәрдә шактый мөһим мәсьәләләр турында сөйләштек. Татарстан җирендә кунакчыллыкның ни икәнен күрдек. Хокук саклау юнәлешендә тәҗрибә уртаклаштык. Проблемалар юк түгел. Азия Омбудсменнар ассоциациясе эшчәнлегенең җәмгыятьтәге әһәмияте зур. Әлеге берлеккә кергән илләр дөнья халкының 60 процентын тәшкил итә, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белешмә

- Азия Омбудсменнар ассоциациясе кеше хокукларын яклау мәсьәләләрен хәл итүдә тәҗрибә уртаклашу өчен мәйданчык буларак оештырыла.
- Ассоциация составына Азиянең 25 иленнән (Пакьстан, Азәрбайҗан, Иран, Кытай, Япония, Малайзия, Индонезия, Корея, Һиндстан, Вьетнам, Үзбәкстан, Әрмәнстан, Грузия һ.б.) 44 әгъза керә, шуларның 9ы – Директорлар советы вәкилләре.
- Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2009 елдан Азия Омбудсменнар ассоциациясе составына керә. Казанда узган чарада Сәрия Сабурскаяны Директорлар советына сайладылар. Биредә ул Россиядән вәкил буларак эшләячәк.

СУЛЫШ КЕБЕК КИРӘК

Урман хуҗалыгы

Саклап тотарга, яңартырга, корткычларны бетерергә, ут якмаска. Татарстан урманчылары республика халкын шуңа өнди. Быелгы язның иртә һәм эссе килүе барыбызны да сак булырга өйрәтте. Җәй дә коры булды. Һава торышын исәпкә алып, быел Татарстан урманнарында янгын куркынычы югары булганга күрә, 5 тапкыр чикләү кертелде. Шул рәвешле урманнар янгыннан сакланды.

Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, инде өч ел рәттән бездә янгыннар күзәтелми. Шулай да быел бер очрак теркәлгән.

– Янгыннарның булмавы – халыкның да уяулыгы нәтиҗәсе. Алар безгә бик ярдәм итә, – ди министр. – Быел Әлмәттә полигон янды. Ялкын урманга якын булган җиргә үрмәләде. Вакытында сүндерелсә дә, быел урман янгынының бер очрагы теркәлде инде. Күрше-тирәләрдә урманнар янганда, без утка юл куймадык. Республикада янгынга каршы тору өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. 25 урман-янгын станциясе эшли. Республика коткаручылары белән берлектә эшлибез. Ел саен янгыннар белән көрәшергә дәүләттән 60 миллион сум акча бирелә. Моның өчен без Татарстан Рәисенә бик рәхмәтле.

Министр илкүләм «Экология» проектының «Урманнарны саклау» төбәк проекты кысасында башкарылган эшләргә дә тукталды. Быел әлеге эшләр өчен бюджеттан 96 млн 197 мең сум акча бүленеп бирелгән. Бу акча агач утырту, орлык запасы туплау, янгынга каршы чаралар һәм урман утырту техникасы алу өчен тотылган. Республикада 3615 гектарда агач утыртылган. Корыганнары яңартылган.

Утыртуын утыртырсың, агачны корт ашаса нишләргә? Быел парсыз күбәләк (шелкопряд) күрмәгәнне күрсәтте. Республиканың төрле районнарында агач яфракларын корт ашап харап иткән иде.

– 2021 елда парсыз күбәләкләр һөҗүме бер булган иде инде. Икенче елны берәү дә күренмәде. Быел бу күбәләкләр тагын килеп чыкты. Чирмешән, Нурлат, Әлки, Алексеевск урманнарына аеруча зур зыян килде. Кайбыч, Тәтеш, Лаеш урманнарында да күренделәр. Хәтта Минзәлә белән Актанышка да барып җиттеләр. Татарстанда әлеге күбәләк 200 мең гектар җиргә зыян салды. Белгечләр парсыз күбәләк кортын Оренбург өлкәсе һәм Башкортстаннан кергән дип аңлата. Безнең урманга керми тор, дип әйтеп булмый. Табигатьнең үз законнары инде аның. Кыш салкын килер дә бетәр дип көтеп кенә утырмыйбыз. Әгәр кортлар күренсә, аларны агуларга да алдан әзерләнәбез. Вакытында кулдан килгәнчә, бөтен мөмкинлекне файдаланып эшләсәң генә алардан котылып булачак, – дип ышандырды министр.

Октябрь аеннан исә урманнарда чистарту эшләре башланачак. «Татарстанның чиста урманнары» акциясе кысасында урман эчләре, юл буйларындагы чүп-чар, калдыклар җыелып алыначак. Язын узган акциядә урманнан 700 кубометр каты көнкүреш калдыклары, 3 мең кубометр чыбык-чабык чыгарылган. Озакламый урман утырту көне дә оештырылачак. Урманчылар 1 миллион данәгә якын кәлшә утыртырга ниятләп торалар.

Урман эшенә яшьләр киләме? Аларның хезмәт хаклары нинди? «ВТ» журналисты министрдан шул хакта сорады. Ник дигәндә, урманда эшләүчеләрнең 90 проценты – ир-атлар. Ә аларга тормыш алып барырга, гаиләсен туендырырга кирәк. Шөкер, 2019 елдан аларның хезмәт хакы күтәрелә башлаган икән.

– Әгәр лаеклы хезмәт хакы түләмисең икән, бу һөнәрне сайлаучы да, урманга килүче дә калмаячак. Әлеге проблеманы Рөстәм Миңнехановка да җиткергән идек. Ул безне аңлады һәм ярдәм итте. Бүген урманчылар уртача 35–45 мең сум хезмәт хакы ала. Хезмәт хакын тагын да күтәрү буенча сөйләшәбез, федераль үзәк белән бергә эшлибез, – дип җавап бирде Равил Кузюров. – Лубян урман хуҗалыгы көллиятен тәмамлап килүче белгечләргә – бер тапкыр 150 мең сум, югары уку йортын тәмамлаганнарга 300 мең сум күләмендә ярдәм күрсәтелә. Әмма алар өч ел урманда эшләргә тиеш. Хәер, урманга бер килгән кеше аннан китми. Бик яратып эшли.

Сүз уңаеннан, 17 сентябрь көнне урманчылар үзләренең һөнәри бәйрәмен билгеләп үтәчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

11445 килограмм орлык та хәстәрләп куйганнар инде. Республиканың **51** питомнигында **30** миллион данәдән артык кәлшә үстерелә. Әле моның янына Саба урман-орлыкчылык үзәгендә җитештерелә торган ябык тамырлы **24** мең данә үсентене дә өстәргә кирәк. Орлык әзерләүчеләр арасында иң актив урманчылыклар Арча, Бөгелмә, Кызыл Йолдыз һәм Сабанчыкылар икән.

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНА – 90:

ЮБИЛЕЙ СЕЗОНЫНДА НИЛӘР КӨТЕЛӘ?

Тинчурин театры яңа сезонын, традиция буенча, 15 сентябрьдә – Кәрим Тинчуринның туган көнендә ачып җибәрәчәк. Юбилей сезонында театр тамашачыларына нәрсә әзерли? Нинди премьералар белән сөендерергә җыена? Матбугат очрашуында шулар турында сөйләделәр.

tinchurinteatr.ru

Тинчурин театры 90 нчы сезонын татар дөньясында бәхәс тудырырга өлгергән «Идегәй» дастаны белән ача.

Башкарылган эшләр һәм яңа сезонга планнар турында театр директоры Фәнис Мөсәгыйтов сөйләде.

– Безнең быел 90 нчы юбилей сезоны. 15 сентябрьдә Туфан Имаметдинов сәхнәләштергән «Идегәй» дастаны белән ачып җибәрәбез. Җәй көне дә эштән туктап тормадык. Август аенда 10 спектакль куйдык, – диде театр директоры.

Аның сүзләренә караганда, театр үзенең юбилей сезонына бик күп үзгәрешләр белән керәчәк. Җиһазлану ягыннан да, репертуар ягыннан да.

– Яңалыклар бик күп. Театр яңара, җиһазлана. Яңа йомшак, уңайлы урындыклар. Ут җиһазлары куелды, бөтен кешегә дә җитәрлек яңа колакчыннар алып кайттык. 3D форматта фотозона ясыйбыз. Бөтен уңайлыклар тудырылган, – диде ул.

Премьералар турында театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов сөйләде. Шамил Фәрхетдинов әсәре буенча «Ай, былбылым» комедиясе 26 октябрьдә күрсәтеләчәк.

– Спектакльдә күбесенчә олы буын артистлары катнаша. Моңсу комедия булачак. Халыкка хәзер кәефне күтәрә торган әйберләр кирәк. Драма, трагедияләр күбәеп китсә, авыррак булыр. Без бик күп районнарга барабыз. Анда күбрәк комедияләрне яраталар. Шул ягы да бар, – диде Туфан Имаметдинов.

Икенче комедия – Мансур Гыйләҗевнең «Көлмәгез, мин үләм» премьерасын декабрь башында күрсәтергә ниятлиләр. Сүз уңаеннан, октябрьдә бирелә Гаилә һәм мәктәп театрларының «Гаилә тарихы», «Театрның яше юк» беренче республика фестиваль-конкурсы узачак. Моннан тыш, 6 ноябрьдә юбилей кичәсе узуы көтелә. Әлеге чараларның барысы да Тинчурин театры оешуга 90 ел тулуга багышлана.

Татарстанның халык артисты Зөлфия Вәлиева өчен бу ел аеруча кадерле. Чөнки быел театрның юбилее гына түгел, аның үзенә – 50 яшь, иҗат тормышына 30 ел булды.

– Шушы өч түгәрәк дата күңелемне бик җылытып тора. Бу ел, Алла боерса, истә кала торган булачак, иҗат тарихыма язылып куелачак. Минем иҗат юлым классик әсәрләрдән башланды. 1993 елда Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романы белән кереп киттем. Аннары инде Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы, Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» спектакле... Шул классик әсәрләр мине гел җитәкләп бара. Сезон ачылганын бик көтеп алдым. Безнең театрга килгән режиссерларның һәрберсе белән эшләп карау бәхете тәтеде. Матур гына иҗат итеп яшәп ятабыз, – диде халык артисты.

Ләйсән САФИНА

ТАТАР КОДЫ

ЯШЬ ПРОГРАММИСТЛАР ТАТАРЧА ИТ-ПРОЕКТЛАР ТӘКЪДИМ ИТТЕ

«Tatar.Бу Хакатон» бәйгесе матбугат хезмәте

Телефон һәм компьютер өчен уеннар, веб-кушымталар, сайтлар... һәм барысы да – татар телендә. Казанның Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-паркында Рәис Бохараевка багышлап «Tatar.Бу Хакатон» бәйгесе уздырдылар. Әлеге чара татар теле һәм әдәбиятын үстерүгә юнәлдерелгән ИТ-проектлар булдыру максатыннан Kazan Digital Week – 2023 халыкара форумы кысасында үткәрелде.

«Хакатон» сүзенә беренче мәртәбә тап булучылар өчен кыска гына белешмә. Бик гади итеп әйткәндә, программистлар ярышы ул. Алар, чикле бер вакыт эчендә һәм үзара ярышып, нинди дә булса проблеманы хәл итәргә тиеш. Бу очракта егет-кызлар татар телен популярлаштыру һәм үстерү өчен тырышты.

Телебезгә битараф булмаган яшь программистлар Татарстан районнары һәм шәһәрләреннән генә түгел, Мәскәү, Санкт-Петербург, Самара, Пенза, Тольятти, Уфадан, хәтта Белоруссиядән үк килгән иде. Җәмгысы 211 гариза кабул ителгән булса, Казанга 96 кеше чакырылган. Нәтиҗәдә кече лигада – 10 команда, өлкән лигада 17 команда көч сынашты. Аларга нибары 42 сәгать эчендә ИТ-проект уйлап табып, аны тормышка ашырырга кирәк иде.

– «Tatar.Бу Хакатон» – Kazan Digital Week – 2023 форумы кысасында уздырылучы дүртенче ярыш. Аның төп үзенчәлеген атамасыннан ук аңлап була. Яшь программистлар тәкъдим итәчәк проектлар татар теленә багышланачак. Икенче үзенчәлек – монда күбесенчә өлкән сыйныф укучылары һәм студентлар катнаша, – диде чараның ачылыш тантанасында Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов.

Телефонда да – Сабан туе

Җиңүчеләрне жюри әгъзалары төрле этаплар һәм финал ярышлары буенча билгеләде. Аларга, акчалата приз белән беррәттән, Татарстан Фәннәр академиясендә стажировка узу мөмкинлеге дә бирелә. Өлкән һәм кече лигаларда җиңүче командалар, проектлары белән таныштыру һәм бүләкләү өчен, Kazan Digital Week – 2023 форумына да чакырыла.

Акчалата приз, димәктән, командаларга ул үз проектларын гамәлгә ашыру өчен бирелде. Өлкән лигада җиңү яулаган командага – 100 мең сум, II урынга – 80 мең сум, III урынга – 55 мең сум. Кече лига җиңүчеләре – 65 мең сум, II урын алган команда – 55 мең сум, III урын алучылар 45 мең сум отты.

Катнашучыларның ике көн дәвамынданиләр майтарганын тагын да яхшырак аңлар өчен, бер проектка тукталыйк. Хакатонда II урынны алган «Тяп-ляп не делаем» командасы «Сабан туе: ат чабышы» дигән уен-кушымта тәкъдим итте. Аны ясаган егетләрнең берсе – Баязит Хәсәнов безгә әлеге кушымтаның үзенчәлекләре турында да сөйләде.

– Уенда без татарлар халкы өчен төп вакыйгаларның берсе – Сабан туен, төгәлрәк әйтсәк, ат чабышын сурәтләдек. Максат – юлда очраган каршылыкларга эләкмичә, туктамыйча хәрәкәт итү. Шулай ук уен барышында өчпочмаклар җыеп була, ә алар ярдәмендә төрле атлар һәм бизәү элементлары алырга мөмкин. Моннан тыш, уенда чәкчәк һәм «КамАЗ» очраячак. Хәрәкәт вакытында төп герой төрле җирлекләр аша үтә: Сабан туе мәйданы, Иске Чәчкаб авылы, яңа төзелә торган М12 юлы һәм Казан шәһәре. Киләчәктә уенга Татарстанның төрле танылган җирләрен кертергә уйлыйбыз. Кушымтаны ике-өч ай эчендә әзерләп бетерергә ниятлибез, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ИДАРӘЧЕЛӘР ДӘ ЯРЫША

Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров «Россия лидерлары» идарәчеләр бәйгесенең округ финалында Татарстан данын яклаучылар белән очрашты. Финалга үткән 63 катнашучы конкурсның төбәк этабы кысасында иң кызыклы тәкъдимнәр әзерләгән.

Бишенче мәртәбә уздырыла торган бәйгедә катнашучылар командалар тупларга, Россия төбәкләре башлыклары тарафыннан янгыраган иң актуаль социаль-икътисадый мәсьәләләрне хәл итү юлларын уйлап табарга тиеш булачак. Рөстәм Миңнеханов Татарстаннан катнашучыларга республикада сәнәгать җитештерүенә ярдәм итү системасын камилләштерү буенча чаралар комплексын эшләргә тәкъдим итте.

Казан Кремлендә узган очрашуда финалчылар республика җитәкчелегенә Рәис тәкъдим иткән бурычны үтәү максатыннан уйлап тапкан идеяләре турында сөйләде. Ә финал үзе 27–29 октябрьдә Түбән Новгородта узачак. Ә ил күләмендәге финал 2024 елның февраленә планлаштырылган.

Очрашу барышында Әсгать Сәфәров Татарстан Рәисенең «Россия лидерлары» конкурсына һәрвакыт зур игътибар бирүен билгеләп үтте һәм финалчыларга әзерләгән тәкъдимнәре өчен рәхмәтен белдерде. Бәйгедә катнашучыларга илнең танылган белгечләре тәҗрибә тупларга ярдәм итәчәк. Аларның Татарстан Рәисенең кадрлар резервына керү мөмкинлеге дә булачак.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге полиция патруль-пост хезмәте аерым ротасы мобиль взводы командиры, полиция капитаны **Микушев** Николай Владимировичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәте полкы 2 батальоны 2 ротасы 2 взводы 3 бүлекчәсе полицейские, полиция өлкән сержанты **Мингалиев** Рәүф Фәйзирахман улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция өлкән прапорщигы **Осипов** Юрий Федоровичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәте аерым батальоны шәхси состав белән эшләү төркеме өлкән белгече, полиция өлкән лейтенанты **Шляндин** Сергей Владимировичка, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы прокуроры урынбасары **Гавриленко** Елена Николаевнага, **Казан шәһәренең «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе коллективына**, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының икътисадый анализ бүлеге башлыгы урынбасары **Ямалиев** Ирек Мансур улына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары **Варакин** Евгений Анатольевич; республиканың финанс системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары **Герасимова** Гела Юрьевна; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Нур» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Харисов** Дәниф Әсрар улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Тәтеш типографиясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Зыятдинов** Ринат Сәйдулла улына, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Татарстан» журналы редакциясе» филиалы шеф-мөхәррире **Сабиров** Әскәр Әсфан улына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Андреев** Сергей Павловичка, «Смәил» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Әхмәдиев** Ильяз Гаяз улына, «Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ферма мөдире (Татарстан Республикасының Буа районы) **Васильева** Лариса Петровнага, «БЕРДӘМЛЕК» авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү һәм сату кулланучылар кооперативы башкарма директоры (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Гайфуллина** Лилия Минталип кызына, «Кама Беконы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 5300 комплексы 2 номерлы цехы башлыгы **Лобашова** Наталья Геннадьевнага, «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең йөк автомобиле йөртүчесе (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Мөнәвиров** Ринат Равил улына, «Сельхозхимия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Нургалиев** Рәис Шаһдәли улына, «Саф» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Шәкуров** Наил Мәгъфүрҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Кама пассажир автотранспорты предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының производство буенча урынбасары **Борһанов** Альберт Фаяз улына, Казан шәһәренең «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе 1 номерлы троллейбус депосы күчмә составны төзекләндерү буенча слесаре (кузовщигы) **Сибагатуллин** Нәфикъ Гомәр улына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Автомобиль юллары идарәсе автомобиль юллары бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Бусова** Наталия Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Усад авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:16:171401) 30.06.2023 ел, № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45 (телефон:+7 (84365) 73-2-75), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 9 октябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45 йорт.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 сентябреннән 2023 елның 9 октябренә кадәр һәм 2023 елның 9 октябреннән 2023 елның 14 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Белдерү

Общество с ограниченной ответственностью Банк «Аверс» (лицензия Банка России № 415; местонахождение: ул. Мусы Джалиля, д. 3, г. Казань, Республика Татарстан, Российская Федерация, 420111; ИНН 1653003601, ОГРН 1021600000993) уведомляет, что 06 сентября 2023 г. внеочередным общим собранием участников ООО Банк «Аверс» (протокол № 198 от 06.09.2023 г.) принято решение о реорганизации в форме преобразования Общества с ограниченной ответственностью Банк «Аверс» в Акционерное общество Банк «Аверс».

Порядок реорганизации кредитных организаций в форме преобразования общества с ограниченной ответственностью в акционерное общество регламентирован Федеральным законом «О банках и банковской деятельности», Федеральным законом «Об обществах с ограниченной ответственностью», Инструкцией Банка России от 02.04.2010 г. N 135-И «О порядке принятия Банком России решения о государственной регистрации кредитных организаций и выдаче лицензий на осуществление банковских операций» и включает в себя следующие основные этапы: принятие решения о реорганизации кредитной организации; уведомление кредиторов о принятом решении; направление документов в Банк России для государственной регистрации кредитной организации, создаваемой в результате преобразования; принятия решения Банком России о государственной регистрации, создаваемой в результате преобразования кредитной организации и выдаче ей лицензии на осуществление банковских операций; внесение в Единый государственный реестр юридических лиц соответствующих записей о созданной в результате преобразования кредитной организации.

Ориентировочный срок завершения реорганизации – декабрь 2023 года. Возможно изменение указанного срока по факту прохождения реорганизационных процедур.

Организационно-правовая форма создаваемой в результате реорганизации кредитной организации — акционерное общество. Место нахождения создаваемой в результате реорганизации кредитной организации: г. Казань, Республика Татарстан, Российская Федерация. Адрес создаваемой в результате реорганизации кредитной организации: ул. Мусы Джалиля, д. 3, г. Казань, Республика Татарстан, Российская Федерация, 420111.

Создаваемая в результате реорганизации кредитная организация предполагает осуществлять следующие банковские операции со средствами в рублях и иностранной валюте: привлечение денежных средств физических и юридических лиц во вклады (до востребования и на определенный срок); размещение привлеченных во вклады (до востребования и на определенный срок) денежных средств физических и юридических лиц от своего имени и за свой счет; открытие и ведение банковских счетов физических и юридических лиц; осуществление переводов денежных средств по поручению физических и юридических лиц, в том числе банков-корреспондентов, по их банковским счетам; инкассация денежных средств, векселей, платежных и расчетных документов и кассовое обслуживание физических и юридических лиц; купля-продажа иностранной валюты в наличной и безналичной формах; осуществление переводов денежных средств без открытия банковских счетов, в том числе электронных денежных средств (за исключением почтовых переводов).

Кредитор ООО Банк «Аверс» – физическое лицо в связи с реорганизацией ООО Банк «Аверс» вправе потребовать досрочного исполнения соответствующего обязательства, а при невозможности досрочного исполнения — прекращения обязательства и возмещения убытков, если такое обязательство возникло до даты опубликования ООО Банк «Аверс» в печатном издании, предназначенном для опубликования сведений о государственной регистрации юридических лиц, сообщения о принятом решении о реорганизации ООО Банк «Аверс».

Кредитор ООО Банк «Аверс» — юридическое лицо в связи с реорганизацией ООО Банк «Аверс» вправе потребовать досрочного исполнения или прекращения соответствующего обязательства и возмещения убытков, если такое право требования предоставлено юридическому лицу в соответствии с условиями заключенного с ООО Банк «Аверс» договора.

Указанные выше требования направляются кредиторами ООО Банк «Аверс» в письменной форме в течение 30 дней с даты опубликования ООО Банк «Аверс» в печатном издании, предназначенном для опубликования сведений о государственной регистрации юридических лиц, сообщения о принятом решении о реорганизации ООО Банк «Аверс» по адресу: ул. Мусы Джалиля, д. 3, г. Казань, Республика Татарстан, Российская Федерация, 420111.

Правление ООО Банк «Аверс»

реклама хокукында

И туган тел, и матур тел...

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ӘРМӘН

ӘТИ СҮЗЕ

Биектау

Туйда тәлинкә вату – бәхеткә. Яңа туган сабыйны алтын әшләнмәләр салынган суда коендыру – муллыкка. Әрмән халкы ырымнарга ышанмаса да, буыннан-буынга күчкән йолаларны үтәргә тырыша. Биектау районының Алан-Бәксәр авылында яшәүче Чапаняннар үз телен, гореф-гадәтләрен саклап, балаларына җиткергән. Әлеге мирасны оныкларына тапшыра алырлармы?

«Капканы бикләмибез»

Чапаняннар авылда – үз кеше. Алан-Бәксәргә килеп төпләнүләренә 21 ел вакыт үткән. Күршеләре белән тату яшиләр. «Безнең ишек төнлә дә ачык. Күршеләр белән аралашабыз. Әмма Татарстанда кунакка әллә ни еш йөрешмиләр. Әрмәнстанда күршеләр туганнар кебек якын. Хәтта кыз белән егетне бер-берсенә өйләндермиләр дә», – ди гаилә башлыгы – 58 яшьлек Вардгес Чапанян.

Әлеге гаилә тырышып ике катлы йорт җиткезгән. Безне ишек төбеннән: «Өебезгә рәхим итегез, «Бари галуст», – дип каршы алдылар. Кунаклар килү – алар өчен үзе бер бәйрәм. Хашлама, виноград яфракларыннан әзерләнгән долма, яшелчәдән шашлык, татлы ризык – гата... Табындагы милли ашамлыклар – барысы да кунакка хөрмәт билгесе. Хуш исле кофе тәкъдим итү дә традициягә әйләнгән.

– Ашны иң беренче булып, күп итеп гаилә башлыгына салабыз. Кечкенә чактан шулай күнегелгән. Без шулай әти, ир хакын олылыйбыз, – ди төп йортка дүрт баласы белән кунакка килгән 37 яшьлек Вардуи.

Һәр атна ахырында әти-әниләренең хәлен белеп, мунча кереп, ял итеп, көч туплап китәләр икән. Бәйрәмнәрне дә бергәләп каршылыйлар.

Икенче йорт

Чапаняннар моңа кадәр Грузиянең Пога авылында яшәгән. Мал-туар тотмаганнар. Ул чакта Вардгес – клуб мөдире. Музыка уен коралларында оста уйнаган. Әмма бер җайга гына яшәп ятканда, тормыш үзгәрә дә куя. СССР таркалгач, хәлләре авырая. Саклык кенәгәсендәге акчалары яна. Гаилә башлыгы башта Самарага барып, фермалар төзү эшендә катнаша. Аннан Татарстанга юл тота. Икең ике якта сагынып яшәп булмый дип, 1996 елда үзе белән гаиләсен алып килә. Төзүче Вардгес Питрәч районының Кавал авылындагы ярдәмче хуҗалыкка эшкә урнаша. Биектау районының «Яңа тормыш» колхозына ферма мөдире кирәк, дип ишеткәч, Алан-Бәксәр авылына күченәләр. Кечкенә генә өйдә яшиләр. Колхоз таркалгач, «Кызыл Шәрык»та биш ел хезмәт куя. Хатыны Варсеник гаилә җылысын саклый, балалар тәрбияли. Тора-бара кибет ачып, үз эшләрен булдыралар. Хәзер аларның ике кибетләре бар.



Милли ризык

Гата

КАМЫР

3 стакан он, 1 стакан кефир, 1 йомырка, 250 грамм маргарин, 3/4 бал кашыгы сода, тәменчә тоз.

Он белән тозны болгатып, соданы серкә белән сүндереп, маргарин, йомырка, кефир кушып, камыр басасы. Өч өлешкә бүлеп, тастымал каплап, ярты сәгатькә суыткычка куеп торырга.

ЭЧЛЕК

1 стакан шикәр комы, 2 стакан он, 250 грамм сыер мае, 50 грамм әстерхан чикләвеге, тәменчә ванилин.

Май белән шикәр комы, онны кушып уыгыз. Блендерда әстерхан чикләвеген ваклап, шунда кушыгыз. Әлеге массаны өчкә бүлегез.

Камырның һәр өлешен уклау белән җәеп, өстенә эчлекне сылап, рулет формасында төрегез һәм ромбиклап кисегез. Өстен йомырка белән майлагыз. Табага пергамент кәгазе җәеп, ромбикларны тезегез. Гатаны духовкага тыгып, 175 градус температурада 20 минут пешерергә кирәк.

Вардгеснең апасы Нвард Анесян да гаиләсе белән әлеге авылда яши. Башка бертуганнары туган якларында калган. Чапаняннар өч бала тәрбияләгән. Кызганыч, уллары яшьли дөнья куйган. Кызлары Вардуи, Гаянэ – әти-әнисенең таянычы. Икесе дә Казандагы сәүдә һәм икътисад университетын тәмамлаган. Вардуи әрмән егете Сурикка кияүгә чыгып, Назели, Саргис, Эдуард һәм өч яшьлек Маньюны үстерә. Биектауда – ТСЖ директоры. Гаянэ әлегә кияүдә түгел. Аңа 33 яшь, башкаладагы җиһазлар кампаниясенең директоры. Узган көз Катарда узган футбол буенча дөнья чемпионатына «Лусаил» һәм «974 нче стадион»ны әзерләүдә катнашкан. Шулай ук республикада ачылган «Адымнар» мәктәпләрен, Әлмәттәге «Орленок» лагерен һәм башка объектларны җиһазлауда да аның өлеше бар.

Шушы вакыт эчендә авылны да, Казанны да, чәкчәк, гөбәдия, өчпочмакны да яратып өлгергән алар. Беркая да китәселәре килми.

Тәрбия

Гаянэ әйтүенчә, гаиләдә ниндидер тыюлар булмаган. Әти-әнисе кызларының иреген кысмаска тырышкан. Әмма артыгын кыланырга ярамаганын белеп үскәннәр.

– Әрмәнстанда ирек мәсьәләсе катырак. Әйтик, сөйгән ярың белән өйләнешкәнче очрашырга ярамый. Әти-әниләр сиңа парны үзе сайлый. Ләкин заманалар анда да үзгәрде, – ди Гаянэ. – Татарстанга килгәч, әти безгә: «Кызларым, сез татарлар арасында яшисез, шуңа күрә аларның телен, гореф-гадәтләрен мәҗбүри өйрәнергә тиеш. Бу – хөрмәт билгесе. Аларны аңлаганда, үзегезгә дә җайлы булачак», – дигән таләп куйды. Безне ике авылда да үз иттеләр, кырын карашны сизмәдек. Татарлар белән туганлашып беттек. Тырышып татар телен өйрәндек. Биектау районы буенча узган олимпиадада рус телле балалар арасында өченче урын яуладым хәтта. Кибеттә бер ел сатучы булып эшләгәндә, авыл апалары, әбиләре белән рәхәтләнеп татарча аралаштым. Апам да татарча белә. Татарстанны бик яратабыз. Монда яшәргә барлык мөмкинлекләр дә бар.

Телне саклау

Татарстанга күчеп килгәч, Вардгес балаларын, туган телне оныта түгел, дип кисәтеп куйган. Урамда – русча, татарча, өйдә бары тик әрмәнчә генә сөйләшкәннәр. Йола, гореф-гадәтләрне дә бергәләп үтәгәннәр.

Вардуи дүрт бала әнисе булгач, туган телне өйрәтүдәге кыенлыкларны күбрәк белә. Алар Сурик белән 11 ел яши. Булачак ире аны интернеттан эзләп тапкан. Сөйгәне хакына Оренбургтан күченеп килгән хәтта. Кызның күңелен тормышны яратуы белән яулаган.

ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР

- Төпчек бала әти-әнисе белән бергә яши. Яңа туган сабыйны беренче тапкыр каенана юындыра. 40 көннән соң гына башкаларга күрсәтергә ярый. Бу көнне гаиләдә бәйрәм уздыралар. Бай булсын дип, баланы алтын бизәнү әйберләре салган ләгәндә юындыралар. Баланы күрергә килгәч, туганнары акча яки бүләк бирә.
- Беренче теш чыккан көнне дә бәйрәм итәләр. Сабыйның башына бодайдан пешерелгән баллы ризыклар сибәләр, алтын куялар. Шуннан соң бәләкәч тартмадагы кәгазьләрнең берсен тартып чыгарырга тиеш. Имеш, анда аның киләчәк һөнәре юрала.
- Балаларны чиркәүдә чукындырганда «Матах» дигән йола үткәрелә. Сарык суеп, 7 фәкыйрь гаиләне ашатырга кирәк. Авырудан яки үлемнән котылганда да шундый ук гадәт бар икән.
- Әрмәннәр – дини халык. Алар үз мәдәниятен саклый. Кайда гына яшәсәләр дә, Әрмәнстаннан «туф» дигән таш кайтартып, чиркәү төзергә тырышалар.
- Туй көнне кәләш белән кияү бусагада аяклары белән тәлинкә вата. Бу бәхеткә дип юрала. Каенана яшь парларны каршылаганда, икесенең дә җилкәсенә ләвәш куя. Ипи белән бал каптыру гадәте бар.

Бәйрәм

Вардавар

Аны 16 июньдә роза чәчәк атканда, гадәттә, елга буенда уздыралар. Бу көнне ат чабышлары, төрле ярышлар үткәрелә. Бәйрәм беткәч, бер-берсенә су сибешәләр. Моңа берәү дә үпкәләми. Әлеге суның шифасына, уңышның мул булачагына ышаналар. Бу көнне алмадан авыз итәләр. Әлеге җиләк-җимеш – мәхәббәт һәм муллык символы.

– Икебез дә – бер милләттән. Өйдә әрмәнчә генә сөйләшәбез. Балалар бакчага, мәктәпкә йөри. Анда мохит – русча. Әлегә туган телне бик белмәсәләр дә, әкренләп өйрәтербез, дип уйлыйм, – ди Вардуи. – Минем бер хыялым бар: Әрмәнстанга барып, җәй буе шунда яшәп, балаларны яхшылап әрмәнчәгә сөйләшергә өйрәтәсем килә. Туган ягыбыз турында китаплар укыйм. Әрмәнчә шигырьләр, җырлар өйрәтәм. Үзебезчә тырышабыз инде.

Сүзгә Гаянэ кушылып: «Әрмән балалары Казандагы Дуслык йортына атнага 2–3 дәрескә йөри. Әнә шулай итеп телебезне сакларга тырышабыз», – ди.

ВИДЕО

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде. Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 327

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+